**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское**
**поселение Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республика**
**Сарман муниципаль**
**районының Иске Имән**
**авыл җирлеге**

---

**КАРАР** **КАРАР**
**16.12.2022 ел** **№65**

Иске Имән авыл җирлеге Советының 2017 елның 12 июнендәге 54 нче номерлы «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсез дип тану тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Иске Имән авыл җирлеге Советының «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсез дип тану тәртибе турында» 2017 елның 12 июнендәге 54 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктның 1.1 пунктында җирле салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- гамәлдән чыгарылган җирле салымнар (реструктуризация режимында һәм банкротлык процедураларында булган салым түләүчеләрнең бурычларыннан тыш);
- бурычның барлыкка килү датасы белән 3 елдан артык түләтеп булмый дигән акт булу;
-01.01.2006 елга кадәр недоимка яки бурычлар булу;
- психикасы бозылган дип суд карары белән танылган затлар;
- картлар йортларында яшәүче затлар;
- иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлар;
- балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче әти-әнисе ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән балигъ булмаганнар;
- ЕВРЮЛДА мәгълүматлары булмаган юридик затлар;
- юридик затларның аны түләттерү вакыты чыкканнан соң недоимкага исәпләнгән пенялар буенча бурычлары булу, недоимка булмаган очракта өстәлгән.

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы “Сарман муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны Сарман муниципаль районы Иске Имән  авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова